МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ № 199/о БОЕРЫК

"15" 11 2018

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 28 ноябрендәге 202/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 202/о номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 6 августындагы 124/о номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының 2018 елның
«15» 11. 2018 № 199/о
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 202/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 202/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибендә:

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып рәсми басылып чыккан Министрлык актлары һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында яки Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актларын аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм алар хакында иҗтимагый фикер алышу максатларында урнаштыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларын аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм алар хакында иҗтимагый фикер алышу максатларында урнаштыру өчен бердәм төбәк интернет-порталында (алга таба – бердәм төбәк интернет-порталы) билгеләнгән мәгълүмат ресурсында (http://tatarstan.ru/regulation) урнаштырылган Министрлык актлары проектлары, Министрлыкта эшләнә торган актларның проектлары тора.»;

3.2, 3.3 пунктларда «Мәгълүмат ресурсында» сүзләрен «бердәм төбәк интернет-порталында» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.3[1] пункт өстәргә:

«3.3[1]. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру нәтиҗәләре буенча коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру максатларында акт проекты

урнаштырылган срок чикләрендә бәяләмә килгән көннән соңгы эш көненнән соңга калмыйча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының ведомствоара электрон документ әйләнешенең бердәм системасында теркәлә.»;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә киңәш итү холкына ия һәм, әлеге Тәртипнең 3.4[1] пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, теркәлгән көненнән башлап 15 көнлек срокта Министрлык структур бүлекчәсе тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш.

Карау нәтиҗәләре буенча коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны уздырган юридик затка яки физик затка нигезле җавап җибәрелә (бәяләмәдә ачыкланган коррупциячел факторлар турында мәгълүмат яки ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш), анда коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алу һәм (яки) норматив хокукый актта яки норматив хокукый акт проектында ачыкланган коррупциячел фактор белән килешмәү сәбәпләре чагылдырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.4[1]-3.4[2] пунктлар өстәргә:

«3.4[1]. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча түбәндәге бәяләмәләр каралырга тиеш түгел:

норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру буенча экспертлар сыйфатында Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында аккредитацияләнмәгән юридик затлар һәм физик затлар тарафыннан әзерләнгән;

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы раслаган формага туры килми торган.

3.4[2]. Әлеге Тәртипнең 3.4[1] пунктындагы өченче абзацта күрсәтелгән очракта, Министрлык структур бүлекчәсе мондый бәяләмәне теркәгән көннән башлап 15 көн узганчы, сәбәпләрен күрсәтеп, кайтарып бирә.»;

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алу әлеге Тәртипнең 3.4-3.4[2] пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.».